Әлмәт муниципаль районы Башлыгы
карары

15 гыйнвар 2020 ел № 02

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 һәм 46 ст. нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Советының 2008 елның 4 апрелендәге 234 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районында гавами тыңлаулар уздыру турындагы Нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге территориясе буйлап уза торган «Җәлилнефть» НГЧИнең Чишмә мәйданында скважиналар төзекләндерү» объекты өчен территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты – 2020 елның 24 гыйнваре 9: 00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Иске Михайловка авыл җирлеге, Ирекле авылы, Урман ур., 1А й.

2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 9А йорт, 3 каб. адресы буенча урнашкан "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесенә территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар тапшырырга.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 2020 елның 24 гыйнваренә кадәр.

3. Иске Михайловка авыл җирлеге башкарма комитетына (Абдуллин И.М.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны тәкъдим итәргә.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы
вазифаларын башкаручы А.А. Зимин